**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.06.2016 Балык Бистәсе штп. № 86пи

2016 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының "Бәтке төп гомуми белем бирү мәктәбе "муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе каршындагы интернатта укучыларның туклануын оештыру турында

Укучыларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту максатларында һәм «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «СанПин 2.4.5409-08не раслау турындагы» 2008 елның 23 июлендәге №45карарын , Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2016 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2015 ел, 23 сентябрь, 698 нче, «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» 2007 ел, 17 декабрь, 721 нче карарлары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.2016 елның 1 гыйнварыннан 2016 елның 31 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының «Бәтке төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет белем бирү учреждениесе каршындагы интернатта (алга таба-интернат) барлык укучылар өчен кайнар аш белән тәэмин итүне оештырырга.

2.Кушымта итеп бирелә торган туклану бәясен исәпләү нигезендә, мәктәп яшендәге бер укучыга көнгә 215,91 сум күләмендә туклану хакын расларга.

3. Интернат укучыларының туклану чыгымнарын финанслауга бер укучыга көненә 40 сум күләмендә, расланган чыгымнар сметасы чикләрендә акча җибәрергә.

4. «Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 елның 17 декабрендәге 721 номерлы карары нигезендә матди карап тору өчен ата-аналар түләвенә чыгымнарны каплауны булдырырга

5. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына муниципаль гомуми белем бирү оешмаларының әлеге карарда күрсәтелгән максатларга чыгымнарының расланган сметалары

чикләрендә җирле бюджетның бюджет ассигнованиеләре хисабына финанс чараларын үз вакытында бүлеп бирүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә һәм 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

8.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р.Х.Хәбибуллин

Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2016елның 8 июнендәге 86 пи
номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы "Бәтке төп гомуми белем бирү мәктәбе»муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе каршындагы интернатта укучыларның туклану бәясен исәпләү**

| № | Продукция исемнәре | Үлчәү берәмлеге | Бер укучыга көнлек норма | 1 кг продукт-ның бәясе (сум.) | Бәя (сум.) |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Арыш икмәге | Грамм | 150 | 32,20 | 4,83 |
| 2 | Бодай икмәге | Грамм | 250 | 33,60 | 8,4 |
| 3 | Бодай оны | Грамм | 40 | 24 | 0,96 |
| 4 | Бәрәңге оны | Грамм | 4 | 56 | 0,22 |
| 5 | Ярмалар, кузаклы, макарон әйберләре | Грамм | 75 | 34 | 2,55 |
| 6 | Бәрәңге | Грамм | 400 | 16 | 6,4 |
| 7 | Яшелчә | Грамм | 475 | 38 | 18,05 |
| 118 | Җиләк-җимеш | Грамм | 300 | 120,00 | 36,00 |
| 9 | Соклар | Грамм | 200 | 50,00 | 10,00 |
| 10 | Киптерелгән җиләк-җимеш | Грамм | 20 | 130,00 | 2,6 |
| 11 | Шикәр | Грамм | 70 | 45,36 | 3,17 |
| 12 | Кондитер әйберләре | Грамм | 30 | 140,00 | 4,20 |
| 13 | Кофе (кофе эчемлеге) | Грамм | 2 | 380 | 0,76 |
| 14 | Какао | Грамм | 2 | 250 | 0,5 |
| 15 | Чәй | Грамм | 2 | 550,00 | 1,1 |
| 16 | Ит | Грамм | 110 | 259,88 | 28,58 |
| 17 | Кош | Грамм | 50 | 130 | 6,5 |
| 18 | Балык (сельдь) | Грамм | 110 | 165 | 18,15 |
| 19 | Казылык әйберләре | Грамм | 25 | 260 | 6,5 |
| 20 | Сөт, әче сөт продуктлары | Грамм | 500 | 44,50 | 22,25 |
| 21 | Эремчек | Грамм | 70 | 146,88 | 10,28 |
| 22 | Каймак | Грамм | 11 | 88,74 | 0,97 |
| 23 | Сыр | Грамм | 12 | 267,75 | 3,21 |
| 24 | Атланмай | Грамм | 51 | 221,85 | 11,31 |
| 25 | Үсемлек мае | Грамм | 19 | 85,00 | 1,61 |
| 26 | Йомырка | данә | 1 | 65,00 | 6,5 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 27 | Тәмләткеч | Грамм | 2 | 20 | 0,04 |
| 28 | Тоз | Грамм | 8 | 9 | 0,07 |
| 29 | Чүпрә | грамм | 2 | 100 | 0,20 |
| Бер тәрбияләнүчегә көнлек туклану бәясе | | | | | 215,91 |

Интернатта укучыларны туклану белән тәэмин итү нормалары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының«Татарстан Республикасы гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив финанслауны кертү турында»2007 ел, 17 декабрь, 721 нче карары нигезендә расланган.